2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

ШАТЛЫК

"Шатлык" балалар бакчасы гәҗите
Сезнең өчен әти - әниләр

№2-2023

Бәйрәмнәр

**Яз бәйрәмнәре:**

***Май чабу бәйрәме***
***8 март - Әниләр бәйрәме***
***21 март - Нәүрүз бәйрәме***
***“Боз озату” бәйрәме***
***“ Карга боткасы”***

**Халык бәйрәмнәре** – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хисләр культурасын тәрбияләргә ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар. Әгәр дә халык бәйрәмнәре югала, юкка чыга икән, бу инде аның рухи байлыклары саега баруын чагылдыра. Халык бәйрәмнәре һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, чөнки җыр, бию, яңа көйләр башкару, очрашу – танышулар шушы көннәрдә булла.

## Карга боткасы

Язгы сабан чоры алдыннан кешеләрне үзара якынайта, хезмәткә дәрт, бердәмлек уята торган тылсымлы йолалар бар минем халкымда. Шуларның берсе – сабанга чыгар алдыннан тау башында учак ягып “ зәрә боткасы” пешергәннәр. Бала – чага билгеләнгән бер көнне өйдән - өйгә йөреп ярма, сөт, йомырка, май җыеп йөргәннәр. Азык-төлек җыеп йөргәндә мондый такмак әйткәннәр: Карга әйтә: кар, кар, Туем җитте, барр, барр, Ярма, күкәй алып бар, Сый, маеңны салып бар. Шулай җыйган ризыклардан тауда зур казанда ботка пешергәннәр. Ул тауны “ зәрә тау башы” дип йөрткәннәр. Олысы – кечесе зәрә боткасы белән сыйланган. Сыйлангач, төрле уеннар уйный торган булганнар. Ямьле язны җылы яклардан кара каргалар алып килә, дип уйлаганнар. Шуның өчен, карлар эреп, сулар ага башлагач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны «Карга боткасы» дип атаганнар.

## Нәүрүз – яз бәйрәме

Җылы нурларын көннән – көн матуррак чәчкән кояшлы, зәп-зәңгәр күк йөзе белән күңелләребезне күтәргән яз килде. Март ае – яз башы, бик матур ай. Бу ай озак заманнар буе Яңа елның беренче ае булып йөргән. Көннең төнне куып җиткән вакытында, Кыш бабайның чәчләре су булып акканда, безнең бабаларыбыз, әбиләребез язны – Нәүрүзбикәне каршылаганнар. Бу көнне үзләренең матур теләкләрен Нәүрүзбикәгә әйтеп калдырырга тырышканнар.

Нәүрүз бәйрәме – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз шатлык, бәхет алып килә.

*Нәүрүз килде, тиз килде,*
*Нәүрүз килде, яз килде.*
*Яз белән муллык килде,*
*Яз белән көрлек килде.*





# “Минем балам татарча сөйләшә”бәйгесе

*Милли тәрбия*

**Балалары белән татар телендә сөйләшүче гаиләләрне барлау максатыннан, «Шатлык» балалар бакчасы «Минем балам татарча сөйләшә» проектына кушылды.**

***17 мартта бәйгенең икенче туры узды. Анда катнашкан һәр гаилә, һәр бала фәкать мактау һәм хөрмәткә лаек. Әти-әниләр дә, балалар да берсеннән-берсе оста һәм матур итеп татарча риваятьләр, әкиятләр сөйләделәр, җырладылар, биеделәр. Милли ризыклар пешерү, милли бәйрәмнәр турында сөйләделәр. Барысы да милли киемнәрдән иделәр.***





***«Шатлык» балалар бакчасы җитәкчесе Илүсә Гамманова әлеге кирәкле проектка нигез салган «Шәһри Чаллы» газетасына, бәйгедә катнашкан гаиләләргә, балаларга, әти-әниләргә, әби-бабайларга, тәрбиячеләргә рәхмәт белдерде. Аны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлзада Рзаева да хуплады. «Шәһри Чаллы» газетасы бик кирәкле эш башкара», – диде.***

***Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Хәмидуллина: «Татар телен камил белгән бу балаларның киләчәге якты булыр. Алар арасыннан язучылар, җырчылар, журналист һәм башка һөнәр ияләре чыгар», – диде.***







**Балалар белән уйныйбыз**

***Татар халкының бик күп уеннары бар. Менә шулар арасыннан җырлы-биюле берничәсен уйнап карарга тәкъдим итәбез.***

### «Чума үрдәк, чума каз»

Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр дә, парлашып, кулга-кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:

***Чума үрдәк, чума каз,***
***Тирән күлне ярата ул, ярата.***
***... үзенә иптәш эзли,***
***Белмим кемне ярата шул, ярата.***
***...не ярата шул, ярата.***

Уйнаучылар җыр ритмына туры китереп, кулларын хәрәкәтләндереп торалар. Ялгыз бала, рәт арасыннан узып үзенә бер иптәш сайлый һәм аны җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы исә рәт башына китә. Җыр яңадан башлангач, ул да үзенә шул тәртиптә иптәш сайлый.

Уен шулай дәвам итә.







### «Түбәтәй»

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлыйлар, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр:

***Түбәтәеңне кигәнсең,***
***Бик ераклардан килгәнсең.***
***Төскә матурлыгың белән***
***Шаккаттырыйм дигәнсең.***
***Туп-туп, түбәтәй,***
***Түбәтәең укалы.***
***Чиккән матур түбәтәең***
***Менә кемдә тукталды.***

Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә.

### «Кәрия-Зәкәрия»

Балалар кулга-кул тотынышып түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:

***Бу бик яхшы биюче,***
***Бу бик яхшы биюче,***
***Аның биюе матур,***
***Аннан үрнәк алыгыз.***

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:

***Кәрия-Зәкәрия, кеммая,***
***Кәрия-Зәкәрия, кеммая,***
***Кәри кемма, Зәкәр кемма,***
***Зәкәрия кеммая.***

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:

***Бу бик яхшы җырлаучы,***
***Бу бик яхшы җырлаучы.***
***Аның җырлавы матур,***
***Аннан үрнәк алыгыз.***

Шулай йөзүче, укучы, буяучы һ.б.



*Балаларга укыгыз!*

***Марзия Фәйзуллина***


## Песи баласы

Кая китеп юкка чыкты
Безнең песи баласы,
Никадәрле эзләсә дә
Табалмады анасы.
Ары чапты, бире чапты,
Күрмн акны, караны.
Мияу, мияу, кайда син, дип
Мыраулап та карады...
Песи баласы мияулап
Килеп чыкты сикереп.
Ул киез итек эченә
Йоклаган икән кереп.



## Казлар

Бер-бер артлы тезелешеп
Казлар күлгә баралар.
- Казлар, кая киттегез? — дип
Сорау бирә балалар.
Казлар шунда бертавыштан:
Елга-га-га-га...— диләр.
Ул елга түгел — күл! — дигәч,
Ул ага... Ага... — диләр.





***Иркә Шакирова***

Юлда ничек йөрисен
Кечкенә булсам да беләм.
Урамда йөрим һаман
Әти- әнием белән.
Машина килгәнен күрсәм,
Йөгереп кырыйга чыгам.
Кич белән беләгемә
"Фликер-беләзек" куям.
Юл аркылы чыкканда
Як-ягыма каранам,
Әниемнән аерылмыйча
Гел житәкләшеп барам.
Светофор утының
Кызылы куша туктарга,
Сарысы "Сабыр ит", ди,
Яшел әйтә: " Кит әйдә!"
ГАИ абыйлар юлда
Тәртип саклап торалар.
Тыңламаган шоферларга
Икеләләр куялар.








**Яр Чаллы шәһәренең 1нче «Шатлык» балалар бакчасы-баланың аң-белемен үстерү үзәге муниципаль автономияле белем бирү учреждениесе**
**Безнең адрес:Яр Чаллы шәһәре**
**Муса Җәлил проспекты 31**
**Безнең сайт:** https://edu.tatar.ru/n_chelny/page92645.htm
**Безнең эл.почта: madou001@mail.ru**